**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **22.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Югары Стәрле авыл җирлегенә
керүче Югары Стәрле авылында 2020 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегендә халык җыены карар бирэ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 150 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Югары Стәрле авылында Октябрь урамынын юлларына щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
- Югары Стәрле авылында юлларны кардан чистарту;

- Югары Стәрле авылында территорияләрне чүп үләннәреннән һәм чүп-чардан чистарту хезмәтләре;;

- янгын депосы бинасына һәм янгынга каршы инвентарь сатып алу һәм ишек урнаштыру;

- Югары Стәрле авылы һәйкәле янында эскәмияләр сатып алу;;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»;

- Югары Стәрле авылы мәдәният йорты өчен сәхнә костюмнары сатып алу.

- «Сабантуй» милли бәйрәмен үткәрү өчен мәйдан оештыру чаралары (элмә такталар, эскәмияләр, чүп-чар өчен контейнерлар сатып алу, җәяүлеләр күперен ремонтлау);

- Югары Стәрле авылында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;

3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Югары Стәрле авылы, Совет., 32г йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,

Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.